Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
башкарма комитеты мәгариф
идарәсенең Вахитов һәм Идел буе
районнары мәгариф булеге

420101, Казан ш., Б.Касимовлар
урамы,6 нчы йорт
Тел./факс (843)224-35-30, 224-30-55
E-mail: roopriv@yandex.ru,
http://edu.tatar.ru/priv/page10198.htm

Отдел Управления образования
Исполнительного комитета
муниципального образования города
Казани по Вахитовскому и
Приволжскому районам

420101, г.Казань, ул.Бр.Касимовых,6
Тел./факс (843)224-35-30, 224-30-55
E-mail: roopriv@yandex.ru,
http://edu.tatar.ru/priv/page10198.htm


**Ана теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган "Туган тел" мастер-класс бәйгесенә**

Казан шәһәре Идел буе районы 127 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы Файзрахманова Фирая Рәшит кызына

**бәяләмә**

Файзрахманова Фирая Рашит кызы 1994 нче елдан Казан шәһәре Авиатөзелеш районының 115 нче урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. 2014 нче елдан башлап Идел буе һәм Вахитов районнарының 127 нче мәктәбендә эшен дәвам итә. Шушы вакыт эчендә ул үзен балаларны, эшен яратучы оста педагог итеп танытты. Аның дәресләре укучыларда зур кызыксыну уята, чөнки Фирая Рашит кызы дәресләргә, бай материал туплап, зур хәзерлек белән керә. Укытучы үз-үзен тотышы, эмоциональ матур сөйләме белән укучыларда туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, ата-анага, өлкәннәргә карата шәфкатьлелек хисләре тәрбияли. Ул укучыларның мөстәкыйль рәвештә фикерләү сәләтен үстерүгә, грамоталы язуларына һәм сәнгатьле укуларына нык игътибар итә. Балаларга шәхес буларак каравы нәтиҗәсендә Фирая Рашит кызының укучылар арасында авторитеты зур. Укучылар аны яраталар, үз итәләр. Ул аларның өлкән дусты да, киңәшчесе дә, сердәше дә.

Фирая Рашит кызы район, шәһәр, республика татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар күрсәтә,

семинарларда чыгышлар ясый. “Яшь ТНВ” телеканалы, “Ялкын”, “Сабантуй” журналлары белән хезмәттәшлек итә. Укучылары “Яшь ТНВ” телеканалының “Без – Тукай оныклары”, “Мәктәп”, “Җырлап татарча өйрәнәбез” тапшыруларында, “Җырлы-моңлы балачак” конкурсында актив катнашып, лауреат исеменә лаек булалар. Шагыйрьләр, язучылар иҗатына багышланган әдәби чараларны, татар теле һәм әдәбияты декадалары, язучылар - Резеда Вәлиева, Шаһинур Мостафин, Булат Ибраһимовлар белән, “Ялкын” һәм “Сабантуй” журналларының хезмәткәрләре белән очрашуларны оештыруда актив катнаша. 6а сыйныфында С.Хакимнең “Бакчачылар” поэмасында хезмәт темасын анализлау” дәресе үткәрелде, А.Алишның туган көненә багышлап күрсәтелгән “Ялкаулык – хурлык, тырышлык - зурлык” исемле сыйныфтан тыш уку дәресе, М. Җәлил, Ш. Галиев иҗатларына багышланган әдәби – музыкаль кичәләр укытучыны үз эшенең остасы итеп исбатлады.

Тырыш хезмәт үз нәтиҗәләрен бирә. Район олимпиадаларында призлы урыннар яулап килгән укучылары районда уздырылган төрле бәйгеләрдә дә актив катнаштылар. К.Насыйри, И.Хәлфин, С.Лихачев, К.Ушинский конференцияләрендә; “Яшь конферансье”, “Илебездә, телебездә Тукай мәңгелек”, “Тукай безнең йөрәкләрдә” кебек бәйгеләрдә Мостафина Диләрә, Гыймадиева Адилә, Һадиева Айгөл, Рубан Илона, Зиннатуллина Ләйсәннәрнең җиңүче булуы һәм призлы урыннар яулавы, иншалар, шигырь бәйгеләрендә катнашып, Мактау грамоталары белән бүләкләнүләре дә; укучылары Гыйләҗева Алсу, Макарова Татьяна , Евлантьева Анналарның районда призлы урын алып, шәһәр һәм республика олимпиадаларында катнашуы да йокысыз төннәре нәтиҗәсе бит! Болар белән ничек горурланмыйсың?! 8нче сыйныф укучысы Зинатуллина Ләйсән Г.Тукайның 125 еллыгы уңаеннан үткәрелгән бәйгедә катнашып район күләмендә 1нче урынны яулады.

Фирая Рашит кызы сочинениеләр, бәйге эшләре тикшерү комиссияләрендә эшли, дәреслекләргә, методик кулланмаларга рецензияләр яза. “Дәрескә технологик карта төзү” темасына авторлык программасы бар. Район укытучылары арасында үткәрелгән “Ел укытучысы” бәйгесендә III һәм IV

урыннарны яулады, ә быел исә һөнәри осталыгын тагын бер кат сынап карап “Үз һөнәренә иҗади якын килүче”  номинациясенә лаек булды. Быелгы уку елында “Татар теле укытучыларының Республиканың Югары уку йортлары арасында үткәрелгән фәнни-методик семинары”нда, Татарстан Республикасында тәҗрибә уртаклашу буенча уздырылган “Татар телен һәм әдәбиятын укытуда ФДГББС куллану”, “Матур әдәбият әсәрләрен анализлауда ФДГББС” дип аталган мастер-классларда катнашты. “Укучыларны V нче Бөтенроссия Тукай укуларына багышланган бәйгегә әзерләү” семинарында катнашып,  сертификат алды. Фәнни – гамәли  конференцияләрдә актив катнашып килүче укытучы буларак ТДГПУ тарафыннан Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Мөгаллимә туктаусыз эзләнә, педагогик осталыгын туктаусыз камилләштерә.

**Идел буе һәм Вахитов районнары**

**мәгариф бүлеге җитәкчесе** **М. З. Закирова**

Управление образования Исполнительного комитета муниципального образования города Казани по Вахитовскому и Приволжскому районам Канцелярия ИНН 1655065593